Бәшәр, Р. Тумыштан килгән талант кирәк / Р. Бәшәр; [әңгәмәдәш] Р. Гасыймова // Шәһри Чаллы. – 2024. – №82 (15 ноябрь). – Б. 7



# Рәшит Бәшәр: «ТУМЫШТАН КИЛГӘН ТАЛАНТ КИРӘК»

**Әңгәмә**

**Ризидә Гасыймова, «Мәйдан»**

**Чаллыда яшәп иҗат итүче балалар язучысы, шагыйрь һәм прозаик Рәшит Бәшәр 75 яшьлеген билгеләп үтте. Күркәм юбилее уңаеннан язучы белән очрашып сөйләшергә насыйп булды.**

## САБАКТАШЛАР - ЯЗУЧЫЛАР

**- Рәшит абый, балачагыгыз Кукмара районы Яңил авылында үткән. Автобиографик әсәрегезне - «Ачык капка»ны укыганым бар. Сугыштан соңгы авыр еллар, шук балачак... Ләкин әсәрдә сезнең ничек иҗат белән кызыксынып китүегез турында сүз юк бит, әйеме?**

- Иҗатка килүем китап белән бәйле булгандыр. Күп укый идек. Укытучыларыбыз да әйбәт иде. Үз фәннәре белән кызыксындыра белгәннәр. Математика дәресендә Мөнир Гомәров дигән егет белән икәү бер партада утырдык. Дәрес вакытында ул рәсем ясый, мин шигырь язам. Аннары, иҗат җимешләребезне конвертка салып, «Яшь ленинчы»га (хәзерге «Сабантуй» журналы), «Ялкын»га җибәрәбез. Басылып чыгалар иде. Конкурсларда җиңдек.

8-9нчы сыйныфларда укыганда Александр Герасимов белән Кукмарага әдәби берләшмәгә йөри башладык. Район газетасы редакциясендә бик яхшы каршы алалар, шигырьләр укыйбыз, сөйләшәбез... Казан университетының татар теле бүлегенә укырга кердек.

**- Һәм шау-шулы студент тормышы башландымы?**

Әйе... Укытучыларыбыз да шәп иде - Хатип Госман, Нил Юзиев, Мөхәммәт Мәһдиевләр... «Әллүки» әдәби түгәрәгенә йөри башладым.

**- Галим Хатыйп Миңнегуловның: «Элек татар бүлегенә укырга күчле шәхесләр килә иде», - дип сөйләгәне бар.**

- Бездән генә дә унлап язучы чыкты бит. Зиннур Мансуров, Рашат Низамиев, Җәүдәт Дәрзаман, Нәҗибә Сафиналар белән бер төркемдә укыдык.

Гаилә коргач, бала тугач, фатир мәсьәләсен уйламыйча булмый. Әлмәт, Лениногорск яклары бик көчле иде ул вакытларда. Укуны тәмамлагач, юллама алып, гаиләбез белән Лениногорскига киттек. Анда фатир мәсьәләсен хәл итү сузылгач, Чаллыга күчтек. Мин КАМАЗ- га диспетчер булып урнаштым. Башта малосемейкада яшәдек, 1983 елда өч бүлмәле фатир алдык.

**- Ул вакытта ничә китабыгыз чыккан иде?**

- Өчәү булгандыр. Беренчесе, балалар өчен, 1975 елда басылды, мин ул вакытта 26 яшь иде. Хәзер барлыгы - егерме.



Фото – Р.Бәшәрнең шәхси архивыннан

**- Сез ни өчен балалар юнәлешен сайладыгыз, Рәшит абый?**

- Бала-чагалык көчле булгангадыр... Минем повестьларда балалар гына түгел, өлкәннәр дә бар бит. Балалар өлкәннәрнең тормышын күрә ала, өлкәннәр, киресенчә, балаларның ниләр уйлап яшәгәнен, дөньяны ничек кабул иткәнен аңлый башлый.

## «БИК ТИЗ ЯЗАМ»

**- Язучы көн саен ким дигәндә бер сәгать язарга тиеш диләр. Сездә бармы андый гадәт?**

- Алай сәгатьләп язган юк. Яза башлыйм икән, тәмамламыйча туктый алмыйм. Һәм бик тиз язам. Беренче «Иртәгә дә яшисе бар» повестемны җиде сәгать эчендә язганымны хәтерлим. «Ачык капка»ны - өч көндә. ...Мәскәүдә укыган вакыт иде. Завуч, берәр әсәр яза башласаң, укырга йөрмәскә рөхсәт итә. Фәиз Зөлкарнәй, мәрхүм, син тәки җибәрмәссең аны дип, повестьны минем машинкада басып, үзе конвертка салып, «Ялкын»га җибәрде.

**- Сез КАМАЗда эшләгәч, Мәскәүгә китеп, Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы ике еллык Югары әдәби курсларда укыгансыз. Кайткач...**

- Чаллыда «Ләйсән» әдәби берләшмәсе белән җитәкчелек иттем. Аннары «Таң йолдызы» газетасына эшкә чакырдылар. КАМАЗ китап нәшриятында, «Ак бүре» киностудиясендә эшләп алдым. Шуннан соң «Аргамак» журналына килдем. «Мәйдан»да эшләп 60 яшемне тутырдым да шундук пенсиягә киттем. «Җитте», - дидем. Аннары инде иҗат белән генә шөгыльләндем.

**- Язучылар арасында көнчелек зур, дип сөйлиләр. Сезнең даирәдә сизелә идеме бу?**

- Минем көнләшергә вакыт булмады. Каләме булган кешене күрергә, ярдәм итәргә тырыштым. Бик күп яшьләргә Язучылар берлегенә керү өчен рекомендацияләр яздым. Нигә көнләшергә? Һәркем үзенең талантына таянып эшли.

**- Язучы өчен иң мөһиме талантмы, әллә тырышлыкмы?**

- Тумыштан килгән талант кирәк. Һәм тормышны белү. Дөрес, талантсызлар да тырыша-тырыша әллә нинди дәрәҗәләргә ирешә.

## «БЕР ҮКЕНЕЧЕМ ДӘ ЮК»

**- Рәшит абый, Люция апа белән сез...**

- Сыйныфташлар.

**- Мәктәпне тәмамлагач, ул - математика юнәлешен, сез әдәбиятны сайлагансыз. Холык-фигыльләрегез дә төрле идеме?**

- Люция апаң математик, икътисадчы, таләпчән, кырысрак. Мин - хыялый. Мине барлап, саклап яшәде инде ул. Авыр булса да, яшь чакта күңелле булган. Безнең заман булган ул. Сагындыра хәзер.

**- Балаларыгыз, оныкларыгыз кайсыгыз юлыннан китте?**

- Улым Ринат КАМАЗда эшли. Соңгы вакытта шигырьләр яза башлады әле. Кызым Лилия медицина өлкәсен сайлады. Оныкларыбыз - финансистлар, программистлар...

**- Яшь чакларны искә алганда, нинди дер үкенечләр, үпкәләр искә төшмиме?**

- Юк, бер үкенечем дә, беркемгә үпкәм дә юк.

**- Туган авылыгызда нигезегез исәнме әле?** Сез **берничә ел буе Яңил мәктәбендә иҗат белән шөгыльләнүче балаларга Рәшит Бәшәр премиясе дә биреп килдегез бит.**

- Булды андый хәл. Ә нигез исән. Авылда бер егет 4 бала белән ялгыз калгач, Рәшит абый, яшәп торыйм әте, дип сораган иде. Уа хәзер безнең нигезгә йорт җиткезде. Кадерсез түгел нигез.

**- Ә хәзер Чаллы мәктәпләренә очрашуларга йөрисезме?**

- Сирәк-мирәк инде. Аның кызыгы да калмады бит, дөресен әйткәндә. Балалар үзара русча сөйләшә. Шуңа күрә чыгыш ясау да кыенрак - аңламаган кешегә сөйләгән кебек. Аннары, китап та укымый, әдәбият белән дә кызыксынмый кебек хәзер балалар. Яшь буын Интернеттан башка нәрсәне белми. И-и, балаларның гына түгел, олыларның да алтындай кадерле вакытын социаль челтәрләр ашый хәзер. Вакытын гына түгел, нервысын да, кешелеген дә...